СОВЕТ КИЛЬДЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КИЛДИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

20.09.2017 | с. Кильдеево | 29-134

Җирле референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22 ст., 56 ст., 20 ст. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 30 ст.1 пункты, Килди авыл җирлеге Уставының 11 ст. нигезендә

Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Килди авыл җирлеге территориясендә җирле референдум уздыруның уртак инициативасын түбәндәге сорау буенча чыгарырга:

«2018 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия булган авыл җирлегенең һәр кешесеннән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә алынган акчалар юлламасына ризалыгыгыз бармы:

- Килди авылы Үзәк урамдагы 250 метр озынлыктагы зиратка керү капкасына кадәр, 2 су үткәргеч торбалар куеп, җирле әһәмияттәге юл төзелеше.
- Уланово авылы Заозерная урамыннан зират ягына 1 су үткәргеч торба куеп вак таш өслекле җирле әһәмияттәге юллар төзү.
- Харино авылы Нагорная урамыннан су башнясы ягына вак таш җәелгән җирле әһәмияттәге юллар салу.

ӘЙЕ ЮК".

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районының
Килди авыл җирлеге башлыгы

В. М. Бурдин